РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» декабря 2019 ел г. Альметьевск № 2140

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетның «Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләренең иректе (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында» 2018 елның 5 сентябрендәге 1319 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 28 ноябрендәге 1425 номерлы карары нигезендә «Федераль башкарма хакимият органнарының, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнарының, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарының, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр буйсынуындагы җирле үзидарә органнарының, башка оешмаларның ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылары һәм ирекле (волонтерлык) оешмалар һәм эшчәнлекләре төрләре исемлеген раслау турында, аларга карата федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге тәртибе раслана торган эшчәнлек төрләре исемлеген раслау хакында», хокукый мониторинг тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы ашкарма комитетының 2018 елның 5 сентябрендәге 1319 номерлы «Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләренең ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ирекләләр эшчәнлеген оештыручы, ирекле оешма, үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру максатларында, җирле үзидарә органнарына, учреждениеләргә һәм (яки) оешмаларга, кертемнәр исемлеге белән яки

Зак. № 305-2000

Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша электрон документ рәвешендә ирекле эшчәнлекне оештыру (алга таба – тәкъдим) өлешендә үзара хезмәттәшлек итү нияте турындагы тәкъдимне (алга таба-тәкъдим) җибәрәләр, анда түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган:

а) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), әгәр ирекле эшчәнлекне оештыручы булып физик зат тора;

б) оешма җитәкчесенең яисә аның вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм контактлары (телефон, электрон почта, адрес), әгәр ирекле эшчәнлекне оештыручы юридик зат булса;

в) юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булган Дәүләт теркәү номеры;

г) нтернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайт яки рәсми бит адресы турында белешмәләр (булган очракта);

д) ирeклелекне (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында булган идентификация номеры (булган очракта);

е) «Хәйрия эшчәнлеге һәм ирeклелек (волонтерлык) турында» Федераль законның 2 статьясы 1 пунктында каралган максатларда ирeклеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эш төрләре (хезмәт күрсәтүләр) исемлеге (алга таба – аларны күрсәтү шартларын, шул исәптән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) күрсәтү срокларын һәм күләмнәрен, әзерлек дәрәҗәсен, компетенциясен, ирекле ярдәмчеләрнең (волонтерларның) белем дәрәҗәсен һәм һөнәри күнекмәләрен тасвирлап, оештыручының тиешле эшчәнлеге, ирекле оешма һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка таләпләр булу тәҗрибәсен тасвирлап».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ә.Б. Ханнанова) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ